СИШӘМБЕ
23
МАРТ
1943 ел.
№ 65 (6787)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ һӘМ КАЗАН ШӘһӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘһӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫН ҮСТЕРҮНЕҢ СУГЫШЧАН ПРОГРАММАСЫ

СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының «1943 елга авыл хуҗалыгын үстерү буенча дәүләт планы турында»гы карары—политик һәм хуҗалык ягыннан гаять зур мөһим документ. Бу карарда колхозларыбызның, совхозларыбызның үткән ел эчендә авыр сугыш шартларында эшләгән эшләренә йомгак ясалган һәм социалистик авыл хуҗалыгын тагын да үстерү буенча сугышчан программа билгеләнгән.

Сугыш колхозлар, МТС лар һәм совхозлар эшендә җитди кыенлыклар китереп чыгарды. Шуңа да карамастан, 1942 нче елда «колхозлар һәм совхозлар көзге һәм язгы чәчүне уңышлы үткәрделәр һәм төп азык культуралары—бөртекле ашлык, бәрәңге, яшелчә һәм шикәр чөгендере чәчүлекләрен шактый арттырдылар. 1942 нче елны Көнчыгышта шикәр чөгендере, клещевина, махорка һәм башка төрле техник культуралар үстерү буенча яңа баштан зур базалар тудырылды».

СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының бу карарында үткән елны авыл хуҗалыгының төп эшләрен һәм дәүләт алдындагы йөкләмәләрне яхшы итеп үтәгән күп сандагы өлкәләр, республикалар һәм крайлар аеруча күрсәтелеп үттеләр. Шул ук вакытта авыл хуҗалыгының төп заданиеләрын канәгатьләнерлек үтәмәгән республика, крайлар һәм өлкәләр дә санала. Шулар арасында безнең Татарстан республикасы да бар. Безнең республикабыздагы күп кенә колхозлар, МТС лар һәм совхозлар үткән елны язгы һәм көзге культураларны чәчү буенча сан заданиесын үтәгән булсалар да, чәчү алдыннан эшкәртүнең сыйфатын түбәнәйттеләр, чәчү срокларын озакка суздылар һәм иген уңышын күтәрү өчен көрәш алып бармадылар.

СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты тарафыннан безнең республикабыз эшенә бирелгән каты бәядән республикабызның партия, совет оешмалары, җир органнары, барлык колхозчылар, совхоз һәм МТС работниклары большевистик нәтиҗә ясарга, үткән елгы ялгышлыкларны, җитешсезлекләрне быел һич тә кабатламаска тиешләр.

1943 нче елга авыл хуҗалыгын үстерү буенча билгеләнгән план безнең колхозларыбызда, совхозларыбызда барлык средстволарны тагын да көчлерәк итеп туплауны, дисциплинаны күтәрүне, оешканлыкны тагын да үстерүне таләп итә. Колхозчылар, МТС һәм совхоз работниклары бу бөек планны фронт заказы, Ватан заказы сыйфатында алкышлап каршы алырлар һәм аны үтәү өчен үз үзләрен аямыйча эшләрләр.

СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты «1943 нче елны иген уңышын күтәрү, бөртекле ашлык һәм башка төрле авыл хуҗалыгы продуктлары җыеп алуны арттыру өчен көрәштә төп игътибар кыр эшләренең сыйфатын күтәрүгә, язгы чәчүне кыска срокларда үткәрүгә, сөрүнең чәчү алдыннан эшкәртүнең һәм чәчүнең сыйфатын яхшыртуга, җирле ашламаларның барлык төрләреннән тулысынча файдалануга һәм чүп үләннәренә каршы, авыл хуҗалыгы культуралары корткычларына каршы көрәш чаралары үткәрүгә юнәлдерелгән булырга тиеш», дип аеруча күрсәтәләр.

Бу бурычларны уңышлы үтәү өчен кыр эшләренә материаль-техник яктан яхшы әзерлекне тәэмин итү таләп ителә. Ләкин безнең республикабызның күп кенә колхозларында, совхозларында, МТС ларында һәм районнарында эшнең бу өлкәсендә гафу ителмәслек җитешсезлекләр, үткән елгы ялгышларны кабатлаулар бар. Югары уңыш алу өчен яхшы орлык кирәк. Ләкин күп кенә районнарыбызда орлык туплау һәм аны тиешле кондицияләштерү эше һаман да төгәлләнмәгән. Язгы чәчүгә кирәк булган кадәр орлык булдыру—һич тә кичектерергә мөмкин булмаган бурыч. Орлыкны һәрбер районның үзендә тулысынча тупларга кирәк. Моның өчен урыннардагы барлык ресурсларны хәрәкәткә китерергә кирәк. Соңгы көннәрдә колхозчылар тарафыннан колхозларга орлык белән ярдәм итү буенча күтәрелгән патриотик хәрәкәт бездә нинди зур мөмкинлекләр барлыгын ачык күрсәтәләр. Масса-аңлату эшләрен тагын да киңрәк җәелдерү нигезендә һәрбер колхозчының колхозга орлык белән ярдәм итүенә ирешү—һәрбер колхозны кичекмәстән яхшы орлык белән тәэмин итү—авылдагы партия оешмаларының һәм совет органнарының бөек бурычы.

Югары иген уңышы алуда җирле ашламалардан файдалану зур роль уйный. Чана юлы өзелгәнчегә кадәр тиресне кырларга чыгаруга, көл, кош тизәге җыюны көчәйтүгә зур игътибар бирелергә тиеш.

Тракторларны, тагылма машиналарны, чәчү вакытына кирәк булган башка авыл хуҗалыгы коралларын әзерләү эше дә күп кенә районнарда гафу ителмәслек дәрәҗәдә начар тора. ВКП(б) райкомнары, район башкарма комитетлары, МТС, совхоз директорлары һәм политбүлек начальниклары, бу өлкәдә булган бөтен җитешсезлекләрне кичекмәстән бетертеп, барлык машиналарны тулы хәзерлеккә китерергә, кыр эшләре вакытында тракторларга хезмәт күрсәтү өчен күчмә мастерскойлар оештыруны булдырырга тиешләр.

СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты тарафыннан куелган бурычларны үтәү өчен колхозлардагы һәм совхозлардагы барлык көчләрне, резервларны хәрәкәткә китерү, аларны дөрес рәвештә урнаштыру таләп ителә. Бу таләп тулысынча үтәлергә тиеш.

Татарстанның партия, совет оешмалары һәм җир органнары СССР Совнаркомының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының бу карарын һәрбер колхозчыга, совхоз, МТС работнигына яхшы итеп аңлатырга, алга куелган бурычларны үтәү өчен социалистик ярышны киң җәелдереп, югары иген уңышы алуны тәэмин итәргә тиешләр. СССР Совнаркомының һәм, ВКП(б) Үзәк Комитетының бу карары колхозчы крестьяннар өчен, авыл хуҗалыгындагы барлык работниклар өчен бөек хәрәкәт программасы, авыл хуҗалыгын тагын да үстерүнең ачык һәм конкрет планы булып тора.

Колхозчылар, колхозчы хатын-кызлар! МТС, совхоз, эшчеләре, авыл хуҗалыгы белгечләре! Авыл хуҗалыгының дәүләт планын үтәү өчен большевикларча көрәшик. Язгы чәчүне тулы әзерлек белән каршылыйк, аны иң кыска срокларда үткәреп, илгә, фронтка авыл хуҗалыгы продуктларын күбрәк һәм күбрәк бирик!

Совет Информбюросыннан

21 нче МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

21 нче мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

***

Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че часть сугышчылары каты сугыш нәтиҗәсендә тимер юл станциясе Вадиноны алдылар. Трофейлар кулга төшерелде. Шулар арасында чигенгән чакта немецлар ташлап калдырган бик күп кораллар бар. Фронтның икенче бер участогында безнең гаскәрләр немецларның көчле итеп ныгытылган бер терәк пунктын алдылар. Бу пункт өчен булган сугышта 200 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде.

***

Белый шәһәреннән көньякта Н-че часть дошманның бер-бер артлы ясалган 5 контратакасын кире кайтарды. Безнең сугышчылар, немецларны хәлсезләндереп, штурм ясап, халык яши торган 6 пунктны алдылар. 400 гә якын гитлерчы, 2 артиллерия һәм 3 миномет батареясы юк ителде. Зенит артиллериясе уты белән немецларның 3 самолеты бәреп төшерелде.

***

Чугуев районында безнең гаскәрләр бик каты оборона сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр. Н-че берләшмә частьлары, дошман танкларының һәм пехотасының зур көчләренең басымын тоткарлап, немецларның 14 танкысын зарарладылар һәм яндырдылар һәм бер батальонга якын гитлерчыларны юк иттеләр. Бер участокта дошман зур югалтулар исәбенә безнең подразделениеләрне бераз кысрыклый алды.

Безнең очучылар дошманның фронт линиясенә килеп җиткән гаскәрләрен бомбага тоттылар. Бер төн эчендә безнең авиациябез немецларның кимендә 10 танкысын, пехота һәм йөк төялгән 60 автомашинасын юк итте. Һава сугышларында немецларның 8 самолеты атып төшерелде.

* * *

Ильмень күленнән көньяктарак Н-че часть дошманны ныгытылган позицияләрдән бәреп чыгарды. Немецлар, элекке хәлне кайтарырга маташып, контратакага күчтеләр, ләкин үзләре өчен зур югалтулар белән алып ташландылар. Сугыш кырында дошманның 300 гә якын үле гәүдәләре калды. Танкка каршы ата торган 5 орудие, 17 пулемет, 2 миномет, күп кенә автоматлар һәм винтовкалар кулга төшерелде.

***

Ровно өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче отрядның партизаннары халык яши торган бер пунктта немецлар гарнизонына һөҗүм иткәннәр. Совет патриотлары 60 гитлерчыны кырып ташлаганнар һәм 15 гитлерчыны плен алганнар. Дошманның 6 пулеметы, 40 винтовкасы һәм 10.000 патроны кулга төшерелгән. Партизаннар немецлар тарафыннан халыктан талап алган 1.000 тонна ашлыкны халыкка кайтарып биргәннәр.

***

Түбәндә Ростов өлкәсенең Матвеев Курган авылында немец-фашист кабахәтләр эшләгән ерткычлыклар турындагы акт игълан ителә: «Кызыл Армиянең ударлары астында чигенгән чакта немец оккупантлар безнең авылда 440 йортны, 5 мәктәпне, театрны, көтепханәне, балалар яслесен, район больницасын һәм башка җәмәгать биналарын җимерделәр һәм яндырдылар. Хәзер авылның 1.000 кешесе йорт-җирсез калды. Кеше ашаучы фашистлар күп колхозчыларны үтергәнче газапладылар. Авылның төрле урыннарында һәм тирә-якларында көн саен немецлар тарафыннан газаплап үтерелгән совет гражданнарының гәүдәләре табыла. Гитлерчы бандитлар безнең районда йөзләрчә намуслы совет кешеләрен ерткыч төстә үтерделәр һәм газапладылар. Аларның һәрберсе өчен без үч алырбыз. Аналарыбызны, аталарыбызны, хатыннарыбызны һәм балаларыбызны үтергән өчен, варварларча кыргый җимерүләр өчен, без немец басып алучылардан үч алырбыз». Актка кул куйдылар: Курган авыл советы председателе Бощенко, колхоз председателе Коробка, Стаценко, партизаннар отряды командиры Косвяненко, типография эшчесе Молчанова һәм башкалар.

***

Чех патриотларының коралланган отряды Карлсбад якынындагы кечерәк бер хәрби заводка һөҗүм иткән. Патриотлар элемтәне өзгәннәр, немец сакчыларны үтергәннәр һәм бинага ут төрткәннәр. 3 цех, әзер продукция тутырылган 2 склад, гараж һәм контора утта янып беткән. Брнода зур бер хәрби предприятиенең механика цехында шартлау булган. Младоболеслава районында чех тимер юлчылар немецларның кораллар төялгән бер поездын юлдан чыгарганнар

21 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

Бик каты сугышлардан соң, командованиенең приказы буенча безнең гаскәрләр Белгород шәһәрен эвакуацияләделәр. Фронтның башка участокларында безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

***

14 нче марттан 20 сенә кадәр үткән атнада һава сугышларында һәм дошман аэродромнарында немецларның 298 самолеты юк ителде. Шул ук вакыт эчендә без 172 самолет югалттык.

***

20 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның кимендә 15 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 200 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 10 кыр һәм зенит артиллериясе батареясының утын бастырдылар, бер сугыш припаслары складын шартлаттылар, бер катерны батырдылар һәм бер батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

***

Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар. Холм-Жирковскийдан көньяк-көнбатыштарак Н-че берләшмә частьлары, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бер пунктны алган чакта ике ротага якын немец пехотасы кырып ташланды, дошманның 6 орудиесе, 3 минометы һәм бер сугыш припаслары склады юк ителде. Күрше участокта безнең частьлар Днепрның көнбатыш ярында плацдармны киңәйтү өчен бара торган сугышларны дәвам иттерделәр һәм халык яши торган 12 пунктны алдылар. Кызыл Армия частьларына партизаннар актив булышлык итәләр. Бер группа партизаннар Залазни авылы якынында урманда засада оештырдылар. Совет патриотлары, дошманның якынлашып килүче обозына каршы ут ачып, бер группа немец солдатларын юк иттеләр. Гитлерчылар белән булган бәрелеш вакытында кулга төшерелгән трофейларны партизаннар Н-че часть сугышчыларына тапшырдылар.

* * *

19 нчы мартта иртә белән дошман Жиздрадан төньяктарак, артиллерия хәзерлегеннән соң, безнең позицияләргә атака башлады. Немецлар сугышка бик күп пехота, танклар һәм авиация керттеләр. Безнең оборона чикләребезгә килә торган юлларда бик каты сугышлар башланып китте. Беренче көнне үк немецларның 9 нчы танк дивизиясенең моторлаштырылган 11 нче укчы полкы тар-мар ителде. Дошманның башка частьлары да зур югалтуларга дучар ителделәр. Икенче көнне немецлар атакаларын яңадан башладылар, ләкин уңышка ирешә алмадылар. Безнең гаскәрләр үз позицияләрен кулларында нык тоталар һәм дошманның җанлы көчләрен һәм техникасын тар-мар итәләр. Тулы булмаган саннарга караганда, сугышларның ике көне эчендә немецлар, үтерелгән хәлдә генә дә 2.000 солдат һәм офицерларын югалттылар. Немецларның берничә дистә танкысы зарарланды һәм яндырылды, 27 орудиесе һәм 70 пулеметы юк ителде. Бу участокта сугышлар дәвам итә.

***

Белый шәһәреннән көньякта безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Н-че часть сугышчылары дошман оборонасының бер терәк пунктын алдылар. Сугыш кырында дошманның 150 дән артык үле гәүдәләре калды. Дошманның бер артиллерия батареясы, 8 пулеметы, бер радиостанциясе һәм сугыш припаслары төялгән 13 повозкасы кулга төшерелде.

***

Чугуев районында безнең гаскәрләр дошман танкларына һәм мотопехотасына каршы бик каты оборона сугышлары алып бардылар. Соңгы көннәрдә немецлар бик күп кешеләрен һәм техникаларын югалттылар. Гитлерчылар, ашыгыч рәвештә яна көчләр китереп, аларны килә-килештән үк сугышка кертәләр. Халык яши торган бер пункт районында безнең сугышчылар дошманның 5 танкысын һәм 200 гә якын солдат һәм офицерларын юк иттеләр. Икенче бер участокта Н-че часть дошманның сан ягыннан өстен көчләренә каршы өч көн дәвам иткән туктаусыз сугышларда дошманның 30 танкысын һәм бронемашинасын һәм бер батальонга якын пехотасын юк итте. Немецлар, безнең частьларны бераз кысрыклап, халык яши торган бер пунктны кулга төшерә алдылар. Ләкин совет сугышчылары соңыннан контратака ясап, гитлерчыларны алып ташладылар һәм элекке хәлне кайтардылар.

***

Кубаньда Н-че часть сугышчылары төнлә белән су чиге аркылы үтеп чыктылар һәм, уңышны тагын да җәелдереп, бер урында немецлар оборонасына эчкәрегә үтеп керделәр. Шул вакытта күрше частьлар дошманны флангларда

(Ахыры 4 нче биттә).

БЕРЕНЧЕ МАЙ АЛДЫ ЯРЫШЫ

АЛДЫНГЫ БРИГАДАЛАР

Балтач районының «Красный труд» артеле коллективы Кызыл Армиянең 25 еллыгы уңае белән алган йөкләмәләрен тулысынча үтәп чыкты. Февраль аенда артель эшләп чыгаруны ике ярым тапкырга арттырды.

Артельнең авыллардагы кустарь бригадалары аеруча яхшы эшләделәр. Мәсәлән, Хәсәншәйх авылындагы иптәш Фәйзерахманова бригадасы февраль ае өчен бирелгән планны 295 процентка, Сәрдегән авылындагы иптәш Кәлимуллина бригадасы 276 процентка үтәп чыктылар.

Хәзер артель һәм аның бригадалары Май алды ярышында да җиңеп чыгу өчен көрәшәләр. Эшчеләрнең күбесе икешәр-өчәр норма бирен эшлиләр. Нормасын үтәмәүчеләр артельдә бөтенләй юк.

Б. КӘРИМОВА.

Бернинди югалту булмасын

Микоян исемендәге фабрика коллективы, социалистик ярышны киң җәелдерү нәтиҗәсендә, мартның беренче яртысында ук айлык планны 145 процентка үтәде. Конфект цехы шул ук вакытта айлык планны 100 процент, шоколад цехы 101, венский цех 179 һәм пряник цехы 58 процент итеп үтәп чыктылар.

Әгәр дә эшкә комачаулый торган кайбер сәбәпләр булмаса, фабрика тагын да зуррак уңышларга ирешкән булыр иде. Ләкин, кызганычка каршы, анда вур җитешсезлекләр бар әле. Фабриканы ягулык белән үз вакытында тәэмин итү мәсьәләсе әле һаман да бөтен кискенлеге белән куелмаган. Булган транспорт көчләреннән дөрес файдаланылмый. Шуның нәтиҗәсендә производствода тоткарлыклар килеп чыга.

Чимал ташу эшләре дә юлга салынмаган. Бу эштә тулы җавапсызлык сизелә. Мәсәлән, соңгы көннәрдә фабрика Волга аркылы Пичицидан Аракчиногта 400 тонна оны һичбер югалтусыз ташып-чыгарып өлгерергә тиеш. Ләкин чимал ташучы агентлар үз өсләренә йөкләнгән бурычларына тиешле җитдилек белән карамыйлар. Шуның нәтиҗәсендә, соңгы икеөч ай эчендә байтак чимал, йомшак итеп әйткәндә, югалтан. Агентлардан Хәйретдинованың 23 килограмм, Әухәдиевның 31 килограмм оны, Борһанованың 12 килограмм оны һәм 35 килограмм бодае, Шишкинаның 15 килограмм оны, Гыйззәтуллинаның 35 килограмм бодае җитешми. Мондый «югалтуларга» чик куелырга һәм гаепләләргә карата закон нигезендә чара күрелергә тиеш.

И. ТУКТАРОВ.

200 ПАР УРЫНЫНА 300 ПАР.

«Спартак» комбинатының унт цехында иптәш Лывина бригадасы балалар йортларында тәрбияләнеп чыккан 14—16 яшьлек кызлардан тора. Кызлар май алды ярышында җиңеп чыгу өчен тырышып эшлиләр. Шуның нәтиҗәсендә бригада сменага 200 пар урынына 300—330 пар аяк киеме эшләп чыгара.

РӘСЕМДӘ: Н-че заводның строгальщигы А. Витвинова. Ул заводка өйрәнчек булып кергән иде. Хәзер катлаулы профессияне үзләштерде һәм көн саен ике норма үти.

К. Тахтеев фотосы.

АРТЕЛЬ ЧЛЕННАРЫ ЙӨКЛӘМӘСЕ

«Точмех» артеле Кызыл Армиянең 25 еллыгына багышлантан социалистик ярышны киң җәелдерү нәтиҗәсендә февраль аенда яхшы гына уңышларга ирешкән иде. Артель коллективы бу уңышларны ныгыту һәм тагын да арттыру теләге белән мартның беренче көннәрендә үк узган айга йомгак ясап, алдагы айдагы бурычларны билгеләде.

— Бөек бәйрәмне производствода тагын да яхшырак эшләү белән каршылыйк,— диделәр эшчеләр һәм бөтен коллектив бердәм рәвештә Беренче Май хөрмәтенә социалистик ярышка чыкты.

Бәйрәм алды ярышы буенча өстәмә йөкләмәләр алынды. Производство планын 20 процентка арттырып үтәү—йөкләмәнең беренче пункты булып тора. Артель ходик сәгатьләр җыюны үзләштергән иде. Хәзер ул моның өчен махсус цех җиһазландырырга, ходик сәгатьләр җыюның дәүләт планын үтәргә һәм массовый күләмдә сәгатьләр чыгара башларга сүз бирә. Моннан тыш коллектив 1 нче майга кадәр сәгать эше буенча 3—4 мастер әзерләргә, оҗыо цехында 20 ләп кешене квалификациягә өйрәтергә, ватан сугышы инвалидларын эшкә өйрәтү мәсьәләсенә аеруча зур әһәмият бирергә йөкләмә алды.

Артель членнары хәзер алган йөкләмәләрен үтәү өчен ныклы көрәш алып баралар. Кайбер мастерлар производствода аеруча яхшы күрсәткечләргә ирешәләр. Мәсәлән, 70 яшьлек карт мастер иптәш Гиллер көнлек нормасын 600—700 процентка кадәр үти. Әхмәдуллин, Тукацейр, Гарвер һәм Пинкин иптәшләр көненә 4 әр–5 әр норма бирәләр. Хатын-кыз мастер Ерусалкина эшләп чыгару нормасын 259 процентка кадәр җиткерә.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

ПАРТИЯ САФЛАРЫН ҮСТЕРҮ БЕЛӘН НАЧАР ШӨГЫЛЬЛӘНӘЛӘР

ВКП(б) Өлкә Комитетының IX пленумы партия сафларын үстерү мәсьәләсенә житди игътибар бирде һәм аны яхшырту буенча практик чаралар билгеләде.

Ләкин, Чепья, Балтач район партия оешмаларының байтагы пленум карарларыннан үзләренә тиешле нәтиҗәне ясамаганнар, партия сафларын үстерү белән һаман да җитди рәвештә шөгыльләнмиләр. Үткән елны, Чепья районында ВКП(б) сафларына кандидат итеп 26 кеше генә кабул ителгән. Шулардан бары 7 кеше генә колхоз партоешмаларына туры килә. «Кызыл юл» колхозы янындагы башлангыч партоешма 1942 нче елда бер генә кеше дә кабул итмәгән. Ә бит бу колхозда үзләрен эштә күрсәткән алдынгылар аз түгел. Ләкин алар белән башлангыч партоешма секретаре иптәш Хәкимова да һәм бу колхозда еш кына булучы район активистлары да бернинди эш алып бармыйлар.

Бу районда ВКП(б) членлыгына кандидатлар арасында политик-тәрбия эшләренең куелышы да бик йомшак. Алар белән аерым беседалар, киңәшмәләр оештырылмый. Күбесенә партия поручениеләре бирелми һәм аларның үтәлеше вакытында тикшерелми, кандидатларның политик белем дәрәҗәләрен күтәрү өчен укулар оештырылмаган.

Партия җыелышлары яшь коммунистларны тәрбияләүдә тиешле зур роль уйный ал. Ләкин кайбер башлангыч оешмаларда җыелышлар бик сирәк үткәреләләр. «Беренче Май» колхозы янындагы партоешманың үткән елның октябрь аеннан бирле гомуми җыелышы булмаган. Биредә агитаторлар да үзләренең эшләрен хәзерге шартлар таләбенә җавап бирерлек итеп оештырмаганнар.

Ленин исемендәге колхоз партоешмасында да (Балтач) 10 айдан бирле партия җыелышлары үткәрелмәгән. Коммунистларга партия поручениеләре бирелми. Партиясез активистлар белән системалы эш алып барылмый.

ВКП(б) сафларына кабул итүне сорап биргән гаризаларны тоткарлау кебек фактлар да бар. Мәсәлән, башлангыч комсомол оешмасы секретаре иптәш Гарифҗанова үткән елдан бирле ВКП(б) членлыгына кандидат булып керергә хәзерләнә. Ләкин аңа рекомендацияләр табуда ярдәм итүче юк. Мондый фактларны Чепья һәм Балтач районы партоешмаларыннан бик күп китерергә мөмкин.

ВКП(б) ның Чепья һәм Балтач райкомнары һәм башлангыч партоешмалар бу җитешсезлекләрне бетерергә, партия сафларын үстерү мәсьәләсе белән җитди шөгыльләнергә, ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы карарларын тормышка ашырырга тиешләр.

Ф. МӘҢГӘРЛЕ.

ЯШЬ КАДРЛАР БЕЛӘН ЭШЛӘҮ

ВКП(б) ның Кызыл юл райкомы җаваплы эшләргә яңа килгән иптәшләр арасында эшләүне киң җәелдерде. Кадрларның белемнәрен күтәрү буенча 9 урында курслар оештырылды. Һәр айны семинарлар һәм киңәшмәләр үткәрелә. Кадрларның эшләренә контроль һәм булышлык ителә.

Яшь кадрлар үзләренең эш участокларында яхшы үрнәкләре күрсәтәләр. Мисал та Шура авыл советы председателе иптәш Баһаветдинованы алырга була. Бу авыл советына 6 колхоз карый. Бу колхозлар 1942 нче елгы хуҗалык эшләрен алдынгылар сафында тәмамладылар. Хәзер 1943 нче елгы язгы чәчүгә әзерлекне киң җәелдерделәр.

Калинин исемендәге колхоз председателе иптәш Шиһапова үзенең политик белемен күтәрү өстендә тырышып эшли. Ул күптән түгел генә партия сафларына керде. Иптәш Шиһапова председатель булып эшли башлаганнан бирле колхоз эше күп яхшырды. Шулай ук колхозчы Мортазина күптән түгел генә Иске Өҗем колхозының партия оешмасы секретаре итеп сайланды. Ул, партоешманың эшен нык-лы план белән алып бара. Бу оешмада учетта торучы коммунистлар колхозның политик-хуҗалык эшләренә актив катнашалар. Колхоз барлык күрсәткечләр буенча алда бара.

С. ҖӘМИЛЕВ.

СУ БАСА ТОРГАН УРЫННАН ПЕЧӘННЕ ТАШУ ТУРЫНДА

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы карары

Су баса торган урыннардагы печәнне ташытып бетерергә кирәклеге турында оешмаларга бирелгән тапкырлар кисәтү ясалуга да карамастан, бу көнгә кадәр аны ташыту оештырылмаган. Бу хәл язгы ташу сулары белән печәннең агып китүенә һәм бозылуына куркыныч китерә.

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы карар бирә:

Барлык печән хуҗаларына кисәтү ясарга: әгәр дә алар су баса торган урыннардагы печәнне 1943 нче елның 1 нче апреленә кадәр ташытып бетермәсәләр, бу турыда гаепләләр җавапка тартылачаклар, ә аларның печәннәре су басуга каршы көрәш буенча Республика Комиссиясе тарафыннан ияссезләндереләчәк һәм башка оешмаларга биреләчәк.

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы Председателе С. ГАФИЯТУЛЛИН.

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы эшләрен идарә итүче С. БРИСКИН.

Казан, Кремль. 19 март, 1943 ел.

ЯҢА ӘПСӘЛӘМ ҖИРЕНДӘ

Кергән хуҗабыз сүзгә юмарт кеше булып чыкты. Өйгә кереп исәнлек-саулык сорышкач та, без аның белән сүзгә бәйләнеп киттек.

— Картың кая соң, әби?—дип сорау бирде янымдагы иптәшем.

— Әйтмә инде... Тозга дип Япырык авылына киткән иде,—дип җавап кайтарды аңарга әби. Тоз турында сүз чыккач иптәшем дә җанланып китте. Бу турыда сүзен дәвам иттерәсе килгән әбигә ул тагын сүз катты.

— Авылыгызда тоз сатмыйлармыни, әби?—дип сорау бирде.

— Юк шул,—дип, бу турыда кооперация работникларының эшлексезлекләренә карата нәрсәдер әйтергә теләгән иде әби. Иптәшем аның сүзен бүлдерде:

— Әби, син бу турыда артык кайгырма инде. Тоз катлавына җитеп киләләр. Тиздән безнең үзебездә тоз бик күп булыр һәм якын тирәдәге башка авыллар да тозга үзләре сезнең авылга килерләр, —дип җавап кайтарды.

Мәфтуха әби дә үзләренең колхоз болынлыгыннан тоз чыгуына ышанычсыз караштан түгел, ләкин ул моны ничек тә тизләтәсе килә иде. Ак гәрәбәдәй таш тозны кирәк саен «Җылы су» тугаендагы шахтадан көянтәләп—чиләкләп кенә алып кайтасы килә.

Бу инде Мәфтуха әбинең дә, Яңа Әпсәләм авылының да уртак теләге. Һәм алар үз басуларында тирән тоз катлавы ятуына да, башка җир асты байлыклары булуга да шик тотмыйлар. Чөнки соңгы ике-өч ел эчендә генә дә бу авыл җирендә колхозчылар, үзләре әйтмешли, ата-бабалары күрмәгән могҗизалы эшләр эшләгәннәр һәм эшлиләр.

Авыл кырыенда борыла-борыла ык суы ага. Аның уң ягыннан текә таулар сузыла. Ул таулар буйлап нефть вышкалары тезелеп киткән. Алардан чыккан кук нефть авыл янындагы тимер юл разъездына китерелә һәм аннан илебезнең төрле почмакларына, промышленность үзәкләренә озатыла.

Менә әзакламый «Җылы су» тугаенда да эш шулай булыр.

Биредә тоз төялгән эшелоннар, олаулар илебезнең төрле почмакларына бер туктаусыз агып торырлар. Әле монда хәзергә казу эшләре бара. Инженер иптәш Ведерниковның әйтүенә караганда, бу урында тоз катлавы ятуы турында яхшы тикшерелгән һәм эшләнгән мәгълүматлар бар.

Шулай ук авыл кырыендагы «Сартүнгәк» басуында да быел зур эшләр бара. Әле үткән ел гына бу урында кыш бер үзе хакимлек иткән. Ул быел да үзенекен итәргә тели. Чокыр урыннарны кар белән күмеп тигезли. Ышык урыннарга өем-өем итеп кар көртләре ясап куя. Ләкин аларга карап биредә эш тукталмый: төзелеш мәйданында кызу эш кайный. Бер урында землянка казыйлар, икенче урында өлгергән землянканың стеналарын сылыйлар, түбәләрен ябалар. Мәйдан уртасындагы кое да өлгереп килә. Машиналар сараена капка куясы гына калган. Төзелеш конторасы һәм ашханә урнашкан зур йорт та шушы кышта гына өлгертелгән. Монда, шулай ук, электростанция дә салыначак.

— Киләсе елга килсәгез, нәкъ менә шушы урында без сезне электростанция ишегеннән каршы алырбыз,—диде төзелеш начальнигы иптәш Варганов ярым шаярту белән. Һәм ул әрем сабаклары һәм шайтан таяклары белән капланган зур мәйданны күрсәтте.

— Аягыгыз җиңел булсын,—дип өстәп куйды ул,—станциянең фундаментын урыныннан беренче көрәк балчыкларны ыргыткан көнне килдегез.

Аннары ул безне станциянең киләчәктәге перспективалары белән таныштырды. Бу станция көче белән якындагы нефть промыслоларына, эшчеләр поселокларына, тоз шахтасына, шушы урында быел салыначак шикәр заводына һәм якын тирәдәге уннарча авылларга хезмәт күрсәтеләчәк. Станция аларга яктылык һәм энергия бирәчәк.

Шулай итеп, Ютазы районының Яңа Әпсәләм авылында бер-бер артлы промышленность предприятиеләре барлыкка килә. Алар бу тирәнең йөзен, күренешен үзгәрткән шикелле, районның экономикасына да зур йогынты ясыйлар. Промышленностьны һаман үстерү, аның өчен чимал чыганаклары булдыру, районда шикәр чөгендере чәчү мәйданын үткән елга караганда 7—8 тапкыр арттыру һ. б.—авылның, районның бик якындагы бай перспективалары әнә шундыйлар.

А. ВӘЛИЕВ.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ ӘЗЕРЛЕК БУЕНЧА ФРОНТ АЙЛЫГЫ

ФРОНТ ӨЧЕН АШЛЫК СУГЫШ КОРАЛЛАРЫ КЕБЕК ҮК КИРӘК

Ә МОНЫҢ ӨЧЕН ЧӘЧҮ ОРЛЫГЫ ӘЗЕРЛӘҮ ШАРТ. АЛДЫНГЫЛАРДАН ҮРНӘК АЛЫЙК. ЧӘЧҮ ОРЛЫКЛАРЫ ҖИТЕШМИ ТОРГАН КОЛХОЗЛАРГА ОРЛЫК БИРЕП ТОРЫЙК.

Беренче нәтиҗәләр

АЗНАКАЙ. Районда чәчү орлыгы туплау буенча фронт декадасы уңышлы гына башланып китте. Районның «Октябрь бүләге» колхозы члены комсомолка иптәш К. Зарипова, колхозга төрле культуралардан 180 пот орлык биреп, районның барлык колхозчыларына ачык хат белән мөрәҗәгать итте.

* * *

ЧИРМЕШӘН. Беренче Май районының «Красное знамя» колхозы членнары декаданың беренче көнендә үк колхозга 486 пот ашлык, 156 пот бәрәңге орлыгы җыеп бирделәр. П. Д. Фролов 36 пот, В. Аришин 36 пот, А. Фролов 30 пот орлык бирделәр.

Куйбышев исемендәге колхоз членнары да колхозга 360 пот ашлык, 240 пот бәрәңге орлыгы туплап бирделәр. Колхоз члены иптәш М. Фомин 36 пот ашлык, 18 пот бәрәңге, иптәш О. Лютина 30 пот ашлык һәм 12 пот бәрәңге бирделәр.

* * *

БАЛЫК БИСТӘСЕ. Чәчү орлыклары җитешми торган колхозлар өчен чәчү орлыклары туплауда колхозчылар зур активлык күрсәтәләр. Туйбахты авыл колхозы члены 70 яшьлек Хәбибулла-иптәш Туктаров 61 пот ашлык, Хәдичә иптәш Ибниева 70 пот ашлык һәм 18 пот бәрәңге орлыгы бирделәр.

СОЦИАЛИСТИК ЯРДӘМ

БАУЛЫ, 22 март. (Телеграф буенча). «Яңа ил» колхозы членнарының инициативасы белән башланып киткән фронт айлыгы Баулы районында да язгы чәчүгә әзерлекне тизләтте. Колхозларда язгы кыр эшләренә әзерлекнең торышы тикшерелде һәм якын көннәрдә тагын нинди эшләр башкарырга кирәклеге билгеләнде.

Мәсәлән, Куйбышев исемендәге колхоз шушы көннәрдә язгы чәчүгә әзерлекне тәгәлләде. Биредә төрле культуралар буенча 373 центнер орлык чистартылып салынды. Авыл хуҗалыгы машиналарына һәм башка инвентарьларга ремонт тәгәлләнде. Колхозда 6 агротехника түгәрәге, 2 зоотехника түгәрәге эшли. Аларда 426 колхозчы төрле эшләргә өйрәнәләр.

Чәчүлек орлык туплау декадасының беренче көннәрендә үк уңышлы гына нәтиҗәләр бар. Колхозчылар үз хуҗалыкларындагы ашлык запасыннан чәчүлек мәйданны орлык белән тәэмин итүне үз өсләренә алдылар. «Урал» колхозы члены, фронтовик хатыны иптәш Сәләхова 6 пот ашлык, 12 пот бәрәңге бирде. Ильясова һәм Габбасова иптәшләр 2 шәр пот ашлык һәм 6 шар пот бәрәңге тапшырдылар. Иптәш Әхмәтвәлиев 15 пот ашлык, 3 пот бәрәңге биреп торды.

Шулай итеп, социалистик ярдәм тәртибендә ике көн эчендә районда 815 пот ашлык, 10.830 пот бәрәңге тупланды.

ГАЛӘВИЧ.

Колхозларның ОРЛЫК ФОНДЫНА

Совет патриотларының взносы

55. ФАРУКШИН Ш.—Шөгер районы, «Үрнәк» колхозы члены—100 пот ашлык кертте.

56. ГӘРӘЕВ С.—Теләче районы, «Кызыл Күкчә» колхозы члены—24 пот ашлык һәм 61 пот бәрәңге бирде.

57. ВАСИЛЬЕВ И,—Теләче районы, «Красный завод» колхозының ат караучысы—12пот ашлык һәм 12 пот бәрәңге бирде.

58. ШМЕЛЕВ А.—Теләче районы, «Красное поле» колхозы члены—чәчү орлыгы алу өчен 80 килограмм бал бирде.

59. КУЗНЕЦОВ А.—Теләче районы, «Самолет № 1» колхозы члены — 9 пот ашлык һәм 12 пот бәрәңге бирде

60. ГАЛИЕВА М. — Теләче районы, «Кызыл Күкчә» колхозы члены—12 пот ашлык һәм 6 пот бәрәңге бирде.

61. ЗИЯТДИНОВА Г.—Теләче районы, «Кызыл Күкчә» колхозы члены—6 пот ашлык һәм 6 пот бәрәңге бирде.

62. САЛАХОВА С.—Балтач районы, «Кызыл игенче» колхозы члены—18 пот ашлык һәм 12 пот бәрәңге бирде.

63. ГАЛИЕВА Г.—Балтач районы, «Кызыл игенче» колхозы члены—18 пот ашлык һәм 12 пот бәрәңге бирде.

64. РАИМОВА — Балтач районы, «Вильтурис» колхозы члены, фронтовик хатыны—12 пот ашлык һәм 6 пот бәрәңге бирде.

65. ГАЛЛӘМОВ—Саба районы, «Кызыл яшьләр» колхозы члены—23 пот ашлык бирде.

ЗАРАРЛЫ ТЫНЫЧЛАНУ

КАРГАЛЫ, 22 март. (Телефон буенча). Кызыл Армия районының «Красный Чирмешән» колхозында ике көн эчендә колхозчыларның үз хуҗалыкларындагы запастан 17 центнер бәрәңге орлыгы җыелды. 80 яшьлек Котельников һәм 65 яшьлек Волкова иптәшләр орлык өчен 90 шар килограмм бәрәңге бирделәр. Колхоз председателе иптәш Нугулов 140 килограмм, колхозчы иптәш Ерофонова 104 килограмм бәрәңге бирделәр.

«Активист» колхозы членнары арасында да орлык туплау уңышлы дәвам итә. Анда ике көндә колхозчылардан 81 центнер бәрәңге тупланды. Полякова, Сухова һәм Аленков иптәшләр берәр центнер бәрәңге бирделәр.

Орлык туплауны районның башка колхозларында да шулай оештырганда, район үзен чәчүлек орлык белән тәэмин итә ала. Ләкин биредә бу эш һич тә канәгатьләнерлек оештырылмаган. Хәзергә кадәр бары 275 центнер бәрәңге, 15 центнер бәрәңге кисентеләре генә җыелган. Нәриман, Ворошилов, Карл Маркс исемендәге һәм «Путь Ленина»колхозларында орлык җыю эше бөтенләй оештырылмаган.

Район җитәкчеләре орлык туплау буенча колхозлар район активы арасыннан 60 вәкил җибәрделәр дә шуның белән тынычланып калдылар. Алар колхозларда орлык туплауның ничек оештырылуы белән кызыксынмыйлар.

Ш. ШАКИРОВ.

БЕР ГЕНӘ БУРАЗНА ҖИР ДӘ КЫСЫР КАЛМАС!

(ВКП(б) ның Әтнә райкомы секретаре иптәш С. Хәсәнов белән беседа).

Соңгы көннәрдә һаваның торышында шактый текә үзгәреш туды: елылык көннән-көн күтәрелә, кырлардагы калкуырак урыннар кардан арына. Яз исе килә. Димәк, югары иген уңышы өчен көрәшнең кызу көннәре—язгы чәчү вакыты килеп җитә.

—Безнең бурыч,—ди иптәш Хәсәнов,—чәчү мәйданының бер генә буразнасын да кысыр калдырмаудан, быел чыннан да хәрби уңыш алуга ирешүдән, фронтны һәм гомумән илебезне авыл хуҗалыгының барлык төр продуктлары белән тагын да мулрак тәэмин итүдән һәм, ниһаять, явыз дошманны илебездән тизрәк куып чыгарудан гыйбарәт.

Барлык колхозларны да югары сыйфатлы орлык белән тәэмин итү югарыда әйтелгән бурычларны тормышка ашыруда нигез шартларның берсе булып тора. Чәчүлек орлык туплау буенча 20 нче марттан 1 нче апрельгә кадәр үткәрелә торган декада бу нигез шартны булдыруда хәлиткеч роль уйнарга тиеш.

Бу гаять әһәмиятле мәсьәләнең торышы безнең районыбызда ничек соң? ВКП(б) Өлкә Комитеты пленумы тарафыннан шул эшкә карата бирелгән күрсәтмәне без ничек үтибез соң?. Башлангыч эш бар, ләкин һич тә җитәрлек түгел әле. Бәрәңге һәм төрле ишелчә культуралары орлыклары белән тулысынча, хәтта артыгы белән тәэмин ителгән булсак та, бөртекле ашлык, терлек азыгы культуралары орлыклары, техника культураларыннан җитен орлыгы белән тәэмин ителү өчен безгә районыбызда шактый тырышып эшлисе бар. Бездә әле орлык гомуми чәчү мәйданының бары 75 процентын капларлык күләмдә генә тупланган. Ләкин соңгы көннәрдә үткәрелгән кайбер чаралар (колхозара орлык алмашуны оештыру, орлык запасларын үлчәп, аларны җентекләп учетка алу, колхозчылар кулындагы запас ашлыклардан бурычка алып тору һ. б.) безнең районыбыз чәчү орлыклары белән үзен тулысынча тәэмин итә алачак дигән ышанычны тагын да ныгыттылар.

Бу уңай белән, башка район работникларына киңәш тәртибендә шуны әйтергә мөмкин: колхоз амбарларында отход дип калдырылган ашлыкларга нык әһәмият бирергә кирәк. Безнең кайбер колхозларыбызда отходка дип калдырылган күп кенә ашлыкларның чәчүлек орлык өчен тәмам ярарлык булганлыкларын күрсәтте.

Хәзер безнең районның 16 колхозы чәчү орлыклары белән тулысынча тәэмин ителгән. Шулардан 14 колхоз орлыклары җитәрлек булмаган колхозларга 2.117 центнер бөртекле ашлык һәм 1.080 центнер бәрәңге биреп торалар, Мәсәлән,Киров исемендәге колхоз 501 центнер бөртекле ашлык, 200 центнер бәрәңге, Ленин исемендәге колхоз 426 центнер бөртекле ашлык, 360 центнер бәрәңге, «КИМ» колхозы 304 центнер бөртекле ашлык бирәләр.

Чәчү орлыклары туплауда колхозчылар актив катнашалар. Район буенча колхозчылар колхозларга чәчү орлыгына 260 пот бөртекле ашлык, 572 центнер бәрәңге, 200 центнер бәрәңге кисентеләре бирделәр. «Электросталь» колхозы членнарыннан Зәйнәп иптәш Хәсәнова 20 пот бөртекле ашлык, Зәйнәп иптәш Абдуллина 9 пот ашлык, 12 пот бәрәңге, Төхфәт иптәш Чәкәнов 2 пот бөртекле ашлык, 18 пот бәрәңге, Әнвәр иптәш Хәбибуллина 15 пот ашлык, 0,5 центнер бәрәңге бирделәр һ. б.

Орлык туплау буенча үткәрелә торган декаданы оештыруда һәм гомумән язгы чәчүгә әзерлекне тизләтүдә колхозларга булышлык күрсәтү өчен район активыннан 80 кеше колхозларга чыгып китте.

Иптәш Фарукшин 100 пот бирде

ШӨГЕР, 22 март. (Телеграф буенча). Республикабызның ялкынлы патриотлары колхоз кырларын чәчүлек орлык белән тәэмин итүнең әһәмиятен яхшы аңладылар. Минзәләлеләр үрнәгендә, гадел хезмәт белән эшләп алган запас ашлыкларын орлык фондына биреп торучыларның саны көннән-көн арта. Менә «Үрнәк» колхозы члены Шәфик иптәш Фарукшин. Ул колхозның чәчүлек орлык фондына 100 пот ашлык бирде.

К. ГУМЕРОВ.

ҮЗ КӨЧЛӘРЕ БЕЛӘН

КУКМАРА, 22 март. (Телефон буенча). «Әзлән» колхозы язгы чәчүгә көздән үк әзерләнә башлады. Анын авыл хуҗалыгы машиналары һәм сбруйлары барысы да әзер. Җирле ашламалар җыюның да кышкы планы үтәлде.

Колхозда чәчүлек орлык җитешми иде. Колхозчыларның булышлыгы бу хәлне яхшыртты.

Чәчүлек орлык туплау декадасының беренче көнендә үк колхозчылардан 129 пот ашлык тупланды. Иптәш И. Касаков 21 пот, Я. Ермолаев һәм Давыдов иптәшләр 9 ар пот, Фәйзуллин, Тукташов, Никифиров һәм Львов иптәшләр 6 шар пот ашлык бирделәр.

Г. ГАЛИЕВ.

УКУЧЫЛАРНЫҢ КОЛХОЗГА ЯРДӘМЕ

Биектау районы, «Пролетарий» колхозының пионерлары һәм укучылары сугылган бодай салымы арасыннан сугылмый калган башакларны сайлап алып, колхозның орлык фондына 8 центнер бодай әзерләп тапшырдылар.

ИЛЕБЕЗГӘ ЯГУЛЫК ҺӘМ ТӨЗҮ МАТЕРИАЛЛАРЫН КҮБРӘК БИРИК!

КУКМАРАЛЫЛАРДАН ҮРНӘК АЛЫП

Кукмара районы колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызларының урман-утын әзерләү планын срогыннан алда үтәү турындагы чакыруларына республикабыздагы күпчелек районнарның урман-утын әзерләүчеләре кушылдылар. Красный бор леспромхозыннан хәбәр итәләр: Красный бор колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары, кукмаралылар чакыруына кушылып, урман кисү һәм ташу планын срогыннан алда үтәү өчен ярышка чыктылар. Алар, дәүләт планын арттырып үтәү белән бергә, немец-фашист ерткычлардан азат ителгән районнарга, андагы җимерелгән шәһәрләрне аякка бастыру өчен, 3.000 кубометр урман әзерләргә йөкләмә алдылар.

***

Чирмешән леспромхозының урман пунктлары, кукмаралылар чакыруын кабул итеп, урман-утын әзерләү планын срогыннан алда үтәргә һәм шуның белән бергә азат ителгән районнарга 1.200 фесметр урман әзерләп бирергә сүз бирделәр.

***

Шәмәрдән леспромхозы май алды ярышына чыгып, конкрет йөкләмәләр алды: март ае планын арттырып үтәргә, азат ителгән районнар өчен, планнан тыш, 1.000 фесметр төзү материаллары, 500 фесметр бүрәнә әзерләргә. Шулардан 300 фесметрын Мичәбаш урман пункты әзерләргә булды.

***

Кайбыч районының утын әзерләүдә һәм ташуда эшләүче колхозчылары кукмаралыларның хатын тикшергәннән соң Беренче Май алды социалистик ярышына чыктылар. Март ае производство планын срогыннан элек үтәү ае итеп игълан ителде.

Урман кисүче һәм ташучы стахановчылар яңа йөкләмәләр алдылар һәм аларны уңышлы рәвештә үтәп баралар. «Кызыл юл» колхозыннан килгән иптәшләрдән Низамова, Мөхетдинова, Аляев, Арсланов, Певичов, Мәхмутова, Идиятов һәм башкалар эшләп чыгару нормасын һәркөнне арттырып үтиләр. Семенов («Маяк социализма» колхозы), Фомина (Молотов исемендәге колхоз), Шәрәфетдинова («Барыш» колхозы), Кудрявцев (Ленин исемендәге колхоз) иптәшләрнең бригадалары график буенча төгәл эшлиләр.

Васильево урман комбинаты алдынгылары

Казан тимер юлының урман заводлары май алды ярышында актив катнашалар. Мәсәлән, Васильево урман комбинаты (начальнигы иптәш Адаменко) производство программасын уңышлы үтәп бара. Иптәш Краснов җитәкчелегендәге бригада заданиене ике тапкырга диярлек арттырып үти. Бригадир Краснов кадрлар әзерләүгә зур игътибар бирә. Ул ватан сугышы вакытында гына да 21 яшь эшчене механика юлы белән бүрәнә ташу эшенә өйрәтте.

Иптәш Подковинский җитәкчелегендәге коллектив оборона әһәмияте булган мөһим заданиене срогыннан бер ай элек үтәп чыкты.

Станокта эшләүче М. Фәтхуллина, күпер төзелеше цехы балта остасы С. Агуреэ, киптерү цехы бригадиры А. Чертова һәм башка уннарча кешеләр сменасына 1,5—2 норма бирәләр.

Совет Информбюросыннан

21 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

әйләнеп үтә башладылар. Бик каты сугышларда безнең гаскәрләр халык яши торган 15 пунктны һәм шул исәптән район үзәге Петровскаяны алдылар. Немецлар Петровскаяны көчле итеп ныгытылган оборона пунктына әйләндергән булганнар. Дошманның югалтулары һәм кулга төшерелгән трофейлар исәпкә алына... Совет очучылары, җир өсте гаскәрләренә актив булышлык итеп, һава сугышларында немецларның 15 самолетын бәреп төшерделәр. Шуның өстенә зенит артиллериясе уты белән дошманның 6 самолеты юк ителде.

***

Гомель өлкәсендә хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды немецларның бер зур авылдагы гарнизонына һөҗүм иткән. Партизаннар 130 дошман солдатын һәм офицерын кырып ташлаганнар һәм немецлар тарафыннан кулга алынган 106 совет гражданнарын азат иткәннәр. Полесье өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды хәрби заданиене үтәгән чакта,аңа немецларның яшерелгән ДЗОТ ыннан ут ачканнар. Отряд зур куркыныч астында булган. Шул вакыт партизанка Рима Шершнева ДЗОТның тишегенә үзенең гәүдәсе белән каплаган. Батыр патриотка геройлар үлеме белән һәлак булган, ләкин отрядның командирын һәм башка иптәшләрен коткарып калган. Партизаннар ДЗОТ эчендәге гитлерчыларны юк иткәннәр һәм хәрби заданиене уңышлы итеп үтәгәннәр.

22 нче МАРТТАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

22 нче мартка каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

***

Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр, халык яши торган күп кенә пунктларны һәм тимер юл станциясе Дуровоны алдылар. Кайбер юнәлешләрдә немецлар контратакага күчтеләр, ләкин аларның атакалары үзләре өчен зур югалтулар белән кире кайтарылды. Бер участокта гына да Н-че часть сугышчылары 200 гә якын гитлерчыны юк иттеләр. 4 орудие, 5 миномет, 13 пулемет һәм күп санда сугыш припаслары кулга төшерелде.

***

Белый шәһәреннән көньяктарак безнең частьлар һөҗүм сугышлары алып бардылар. Н-че берләшмә сугышчылары халык яши торган көчле ныгытылган 2 пунктны алдылар. Бу пунктлар өчен барган сугышларда немецларның 2 танкысы җимертелде, танкка каршы ата торган 5 орудие, 17 автомашина юк ителде. Халык яши торган бу пунктларның урамнарында немец солдатларының һәм офицерларының 275 үле гәүдәсе калды. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды Икенче бер участокта безнең разведчикларның бер отряды халык яши торган бер пунктка бәреп керде һәм анда булган гитлерчыларны кырып бетерде. Разведчиклар дошманның сугыш припаслары тутырган 2 складын шартлаттылар һәм югалтуларсыз үз частьларына кайттылар.

***

Чугуев районында безнең гаскәрләр каты оборона сугышлары алып баруны дәвам иттеләр. Н-че берләшмәнең частьлары дошманның берничә атакасын кире кайтардылар, 5 танкысын юк иттеләр, 400 гә якын немец солдатын һәм офицерын кырып ташладылар. Икенче бер участокта гитлерчылар безнең подразделениеләрне кысрыкларга һәм су чиген үтеп чыгарга күп тапкырлар маташтылар. Нык оборона белән безнең сугышчылар немецларның барлык атакаларын да кире кайтардылар. Иптәш Козюлин җитәкчелегендәге гвардеецлар кичә немецларның 3 танкысын яндырдылар һәм бер ротадан артык пехотасын юк иттеләр.

***

Ильмень күленнән көньяктарак Н-че часть подразделениеләре төнлә дошманга атака ясадылар һәм аны ныгытылган позицияләрдән бәреп чыгардылар Сугыш кырында дошманның 100 дән артык үле гәүдәләре калды 7 пулемет, 2 миномет һәм сугыш припаслары склады кулга төшерелде. Иптәш Кутузов командалыгындагы разведчиклар дошман тылына үтеп керделәр, 20 гитлерчыны кырып ташладылар һәм исән-сау үз частьларына кире кайттылар.

***

Ленинград фронтында безнең очучылар һава сугышларында һәм дошман аэродромнарында 22 немец самолетын юк иттеләр.Моннан башка зенит артиллериясе уты белән дошманның 12 самолеты бәреп төшерелде.

***

Киев өлкәсе районнарының берсендә хәрәкәт итүче партизан отряды сугыш хәрәкәтләренең бер атнасы эчендә кыр жандармериясе батальонын җитди югалтуларга дучар иткән. Шушы ук вакыт эчендә совет патриотлары берничә күперне шартлатканнар, бер паровозны юк иткәннәр һәм 82 тимер юл цистернасын яндырганнар. Бу цистерналарның кайберләренә ягулык тутырылган булган. Партизаннар дошманның 18 пулеметын 107 винтовкасын, 12 пистолетын һәм күп санда сугыш припасларын кулга төшергәннәр.

***

Немец-фашист кабахәтләр Белоруссиядәге Полесье өлкәсе Ветчины авылында коточкыч явызлыклар эшләгәннәр. Авылга килгән немец җәза отряды барлык ирләрне, хатын-кызларны һәм балаларны 3 зур сарайга куып япкан. Гитлерчы палачлар сарайга ут төрткәннәр һәм андагы кешеләрне тере көйгә яндырганнар. Качарга теләүчеләрне немецлар пулеметлардан атканнар. Фашист ерткычлар кулыннан авыл халкының күбесе һәлак булган. Бары тик алдан авылны ташлап киткән һәм урманнарга качкан семьялар гына исән калганнар.

22 нче МАРТТАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

22 нче мартта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

***

21 нче мартта безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 20 гә якын танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 дән артык автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 6 сугыш припаслары складын шартлаттылар, 10 кыр һәм зенит артиллериясе батареясының утын бастырдылар.

***

Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че часть сугышчылары, каты сугышлар нәтиҗәсендә, дошманны Днепр елгасы чигеннән алып ташладылар. 400 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. 4 орудие, пулеметлар, винтовкалар, сугыш припаслары, 8 тягач, 25 автомашина һәм башка төрле сугыш милекләре кулга төшерелде.

***

Җиздрадан төньякта артиллерия һәм миномет уты белән шулай ук совет пехотасының контрударлары белән дошманның берничә бик каты атакасы кире кайтарылды. Немецлар безнең оборона линиясен өзәргә маташалар, ләкин бу маташулар уңышсыз бетәләр һәм дошман авыр югалтуларга дучар була. Сугышларның өч көне эчендә бу участокта дошманның 5.500 солдат һәм офицерлары үтерелде. Һава сугышларында һәм зенит артиллериясе уты белән немецларның 11 самолеты атып төшерелде.

***

Белый шәһәреннән көньяктарак безнең гаскәрләр, һөҗүмне дәвам иттереп, халык яши торган 40 пунктны алдылар. Бер биеклек районында аеруча каты сугышлар булды. Бу биеклекне дошман көчле каршылык күрсәтү узелына әйләндергән булган. Н-че часть сугышчылары, оста маневр ясап, немецларның оборонасын җимерделәр һәм биеклекне алдылар. Дошманның җиргә казып куелган берничә танкысы, артиллерия һәм миномет батареялары, шулай ук башка трофейлар кулга төшерелде.

***

Белгород районында безнең гаскәрләр дошман танкларына һәм мотопехотасына каршы оборона сугышлары алып бардылар. Немецларның безнең оборонабыз аркылы үтәргә маташулары уңышсыз чыкты. Н-че берләшмә частьларының уты белән дошман туктатылды һәм зур югалтуларга дучар ителде Бер участокта гына бер батальонга якын немецлар юк ителде, дошманның 8 танкысы зарарланды һәм 5 танкысы яндырылды. Икенче бер районда су чиген үтәргә маташкан гитлерчыларның барлык атакалары кире кайтарылды.

***

Ростов-Доннан көнбатыштарак дошман иптәш Пономарев подразделениесе саклап тора торган участокка атака ясады. Немецларның якынрак килүләрен көтеп торып, безнең сугышчылар залп уты ачтылар һәм 100 дән артык гитлерчыны кырып ташладылар.

Совет очучылары һава сугышларында немецларның 4 самолетын бәреп төшерделәр һәм 2 самолетны зарарладылар.

***

Смоленск өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды 300 совет гражданын каторга эшләренә алып баручы немец солдатларына һөҗүм ясаган. Партизаннар, немецларны үтереп, совет гражданнарын фашистлар коллыгыннан азат иткәннәр һәм 8 автомат, 40 винтовка кулга төшергәннәр. Икенче көнне бу отряд немецларның бер җәза отрядына һөҗүм иткән. Сугыш нәтиҗәсендә партизаннар 100гә якын немец солдатларын һәм офицерларын кырып ташлаганнар.

***

Смоленск өлкәсе, Давыдково авылы укытучысы Татьяна Оглоблина немец-фашист кабахәтләренең ерткычлыклары турында түбәндәгеләрне сөйләде: «3 нче мартта немецлар, ату белән куркытып, Давыдково, Астафово, Арденово, Тазово, Дровники, Курово, Черепки һәм башка авылларның барлык кешеләрен тылга куып алып киттеләр. Безгә җыенырга 10 минут вакыт бирделәр. Төнге сәгать 1 гә без Минкино авылына барып җиттек һәм ачык һавада йокларга тукталдык. Безнең баштан кичкән газапларны әйтеп бетерергә мөмкин түгел. Балалар гына түгел, олылар да еладылар. Көндез сәгать 1 дә немецлар безне барыбызны да тагын да арырак куып алып киттеләр. Алар, безне тизрәк барырга мәҗбүр итү өчен, ашыктырдылар, ату белән курkyттылар. Артта калучыларны мылтык түтәләре белән кыйнадылар. Немецлар берничә тапкыр ут ачтылар. Без Кызыл Армия частьларының якында гына икәнлеген белә идек һәм шунлыктан мөмкин кадәр акрынрак барырга тырыштык. Без Царево-Займище авылына килеп җиткәндә бик якында гына «ура» тавышлары ишетелде. Немецлар шунда ук качтылар. Без барыбыз да землянкаларга һәм блиндажларга ташландык. Озак та үтми без үзебезнең туган телебездә сөйләшүне ишттек. Авылга кызылармеецлар килеп керделәр. Бу — онтылмаслык очрашу булды. Совет сугышчылары безне котылгысыз куркынычлы һәлакәттән коткардылар.

ФРАНЦИЯ ХАЛКЫНЫҢ ОККУПАНТЛАРГА КАРШЫ КӨРӘШЕ КӨЧӘЯ

ЛОНДОН, 21 март. (ТАСС). Сугышучы Франция даирәләренә алынган хәбәрләргә караганда, Виши властьлары, 1939—1940 нчы елларда гаскәри хезмәткә барырга тиешле яшьләрне Германиягә җибәрү өчен, аларның исемлекләрен төзи башлаганнар. Виши «хөкүмәте» иң беренче чиратта Германиягә Франциянең патриотик эшчеләрен, профсоюз оешмаларының элекке активистларын һәм башка «ышанычсыз элементларны» җибәрергә омтылалар.

Франциянең бик күп шәһәрләрендә массовый облавалар дәвам итә. Бу облавалар вакытында французлар белән гитлерчылар арасында кан коелышлы бәрелешләр бара. Шушы көннәрдә Лионның заводлар районында бер группа французлар немец солдатлары отрядына гранаталар ыргытканнар. 29 немец үтерелгән һәм авыр яраланган. Граната ыргытучылар качканнар.

Германиягә җибәрү өчен эшчеләрне туплауга Франция халкының каршылык күрсәтүе торган саен көчәя бара. Германиягә каршы диверсияләр һәм немецларга һөҗүм итүләр көннән-көн арта. Валанс шәһәре белән Вьены шәһәре арасындагы тимер юлда немецларның шартлый торган әйберләр төялгән бер эшелоны шартлатылган. Шартлау нәтиҗәсендә немецларның барлык поезд составы һәлак булган. Бу поезд җибәрелергә әзерләнгәннән соң 3 көн буена станциядән чыгып китә алмаган, чөнки Франция патриотлары берничә урында тимер юлны шартлатканнар. Парижда 30 га якын немец солдаты төялгән бер йөк машинасына граната ташланган. Немец солдатлары арасында үлүчеләр һәм яраланучылар бар. Соңгы берничә көн эчендә Согласие мәйданында немецларның 30 офицеры үтерелгән. Күптән түгел патриотлар Марсель янында немецларның хәрби материаллар төялгән бер поездын юлдан чыгарып аударганнар. Бу участокта тимер юл хәрәкәте 7 сәгать буена тукталып торган.

Германиянең Норвегиядәге частьларында дезертирлык

ЛОНДОН, 20 март. (ТАСС). Швеция-Норвегия матбугат бюросының хәбәр итүенә караганда, Норвегиядә Германия частьларының берсеннән 630 немец солдаты качып киткән. Бу частьның СССР га каршы сугышка фронтка җибәреләчәге турында мәгълүм булгач, немец солдатлары арасында ризасызлык башланган. Күп кенә солдатлар фронтка барырга теләмәгәнлекләрен ачыктан-ачык белдергәннәр. Шул уңай белән бу частьта күп кенә солдатлар кулга алынган. Аларның бик күпләре атып үтерелгәннәр.

ЧИТ ИЛ ХРОНИКАСЫ

—Югославиянең Пожаревац шәһәрендәге тимер юл транспортында бик зур саботаж актлары ясалган. Немецлар патриотлардан үч алу нияте белән 400 кешене атып үтергәннәр. Шул районда булган Топаница авылы бөтенләй яндырылган һәм анда торучы кешеләр атып үтерелгәннәр.

—Бельгиянең бер группа патриотлары шушы көннәрдә Брюссель шәһәрендә Германиянең эш көчләре җыя торган бюросына һөҗүм итеп кергәннәр һәм Германиягә җибәрелергә билгеләнгән эшчеләрнең барлык исемлекләрен һәм адресларын юк иткәннәр.

—Гитлер властьлары күптән түгел Франциянең Нор һәм Па-де-Кале департаментларында 30.000 тонна ашлыкка, 25.000 тонна иткә һәм 15.000 тонна шикәргә конфискация ясаганнар. Марсель шәһәрендә немецлар авыру балалар өчен билгеләнгән барлык азык продуктларын талап алганнар.

ПОЛЬШАДА ЗАБАСТОВКАЛАР

ЛОНДОН, 21 март. (ТАСС). Польшадан алынган хәбәрләргә караганда, соңгы-вакытта гитлерчы оккупантларга каршы Польша халкының каршылык күрсәтүе көчәеп киткән. Польшаның күп кенә заводларында һәм шахталарында забастовкалар бара. Күптән түгел Радам промышленность районындагы заводларның берсендә бик зур забастовка булган. Гитлерчылар бу заводка немецлар тарафыннан куелган управляющийны үтерүдә гаепләнгән 300 полякны атып үтергәннәр. Забастовка 3 көн дәвам иткән. Германия полициясе һәм гестапо отрядлары, эшчеләрне эшкә көчләп куып җибәрү өчен, аларның квартираларына кереп йөргәннәр. Забастовка ясаган эшчеләр белән гитлерчылар арасында канлы бәрелешләр булган. Шул чакта немецлар пулеметлардан һәм броневиклардан атканнар.

Барановичида фашист палачларны үтерү

СТОКҺОЛЬМ, 20 март. (ТАСС). Гитлерчылар тарафыннан чыгарыла торган «Минскор цейтунг» газетасының хәбәр итүенә караганда, Барановичида совет партизаннары бу шәһәргә гитлерчылар тарафыннан куелган «баш комиссар» Фридрих Фенчны һәм сакчы отрядлардан берсенең башлыгын үтергәннәр.

Җаваплы редактор
И. ҮЗБЕКОВ.

ТЕАТРЛАРДА ҺӘМ КИНОЛАРДА

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. Бүген премьера — **«Эрджикинез»**.

Зур драма театры. Бүген — **«Маскарад»**.

Яшь тамашачылар театры. 24 нче мартта — **«Мәзәкчеләр»**. Кич 7 сәгатьтә башлана.

Дәүләт циркы. Бүген зур цирк тамашасы. Кич 8 сәгатьтә башлана.

«Электро» — яңа документаль фильм — **«Сталинград»**. Унион — көндез һәм кич — **«Моряк кызы»**. «Пионер»—көндез — **«Руслан һәм Людмила»** һәм **«Боксерлар»**, кич— **«Минем мәхәббәтем»**. «Чаткы» — көндез — **«Әкиятләр»**, кич — **«Фронтка концерт»**.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретариат һәм авыл хуҗа лыгы бүлеге 79—29, промышленность, транспорт, партия тормышы һәм хатлар бүлекләре—73—27, типография 36—60.

ПФ 968«КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 1531